Кичке иманнар

Атанын, Улнын, Святый Тыннын исеменя, аминь.

Эй Ходайым, Іисусъ Христосъ Алла Улы, мин жазыклыны жарлыка.

Эй Алла мин жазыклыга изгелекле бул.

Шөкөр Синға, эй Аллабыз шөкөр Синға.

Кюк Падшасы, жанга тынычлык, кюнелгя чын белем биреўче Тын, кайда булса да бар Син, барында өлгөрттрясең, ăр-төрлө жакшылыкка бай Син, терелек биреўче Син Ўзең, безгя килеб урыннаш, безнен яр-бер шакшылыгыбызны ăрче, жаннарыбызны коткар, Син изгелекле.

Святый Алла, Святый Кодрятле, Святый Ўлемсез, безне жарлыка. *(3 табкыр).*

Шөкөр Атага, Улга, Святый Тынга, ăле дя ăр чакта да гумердян гумергя, аминь.

Эй инг Святый Өч Ипостасьле Алла, безне жарлыка; эй Ходай, безне жазыктан тазарт; эй безне тотоб Тороучы, законынгнан жазганыбызны кичер; эй Святый, безгя изгелек

кылыб, безнен житешмягян жиребезне тӧзят, Ӱз исемең ӧчӧн.

Эй Ходай жарлыка. *(3 табкыр).*

Шӧкӧр Атага, Улга, Святый Тынга, әле дя әр чакта да гумердян гумергя, аминь.

Эй Кюктяге Атабыз! Данны булыб торсон исемең Синең, килсен падшалыгың Синең, жирдя дя кюктягечя булсын иркең Синең. Бӧгӧн көннӧк икмягебезне бир безгя. Бурычларыбызны кичер, без дя безгя бурычлы булганнарга кичергян кюк. Безне алданырга ирек жибярмя. Жаманнан коткар безне.

Безне жарлыка, эй Ходай безне жарлыка, без жазыклылар ӱзебезне дӧрӧслярга бер жауаб та биря алмагач, тик Син безне Тотоучыга шушылай гна инялябез, эй Ходай безне жарлыка.

Шокор, Атага, Улга, Святый Тынга да,

Эй Ходай безне жарлыка, Синға ӧмӧтлянеб торабыз, безгя каты ачыуынгны китермя, законынгнан жазганыбызны исендя тотма, эй изгелекле Ходай, әле безгя кюзеңне сал, дошманнарыбыздан безне коткар, безнен Аллабыз Син, без Синең кешелярең, Ӱз кулың

белян булдырганнарыңг, Синеңг исеменя сыйынабыз.

Әле дя әр чакта да гумердян гумергя, аминь.

Алланы тыудырган изгелекле Мария, изгелек ишеген ач безгя, без Синңа ышаныб торганнарны жугалттырма, бялялярдян коткар, Син Ўзеңг Христоска ышаныучыларны котолдороучы.

Эй Ходай жарлыка, *(12 табкыр).*

1-нче иман, изге оло Макарийнеке

Эй мянге Алла, эй бар булдырылганнарнын Падшасы, мине бу сагяткя житешергя тейешле кюреўче, бögön эш белян дя, сюз белян дя уй белян дя кылган жазыкларымны минга кичер, эй Ходай, минем мескен жанымны да, тянемне дя, тынымны да әр-төрлö шакшылыгыннан тазарт. Эй Ходай, бу төннö тыныч жоклаб ўткязергя минга булыш, мин жарлы гна урнымнан тороб, гумеремнен бар көннярендя дя Синеңг арыу исеменгне даннасам ыйы, шулай итеб минга карышылык итеўче тянне-тянсез дошманнарны жинсям эйе. Эй Ходай, мине шакшыландыра торган жаман няпеслярдян, буш уйлардан мине коткар, эй Ата, Ул, Святый Тын, падшалык, кыуат ололок

Синеке әле дя яр-чакта да гумердян гумергя, аминь.

2-нче иман, изге Антиохныкы. Ходай Иисусъ Христоска

Эй барында Тотоучы Алла Сюзе, эй иң кядерле Іисусъ Христосъ, Ўзеңнен кюб изгелеген какына мин мяндяңне ташлама, әммя жалан минем белян була кюр. Эй Ўзеңнен сарыкларыңны арыу көтөўчы Іисусъ, мине жыланнын усаллыгына ирек бирмя, мине шайтан иркеня калдырма, миндя ўлем орлого бар шул. Эй без табына торган Алла Ходай, изге Падша Іисусъ Христосъ, Ўзеңнен бетмей торган жактың белян, өйрянеучеляреңне арыулан-дырган Святый Тыныҥ белян мине жоклаган чагында сакла. Эй Ходай, жоклаган урнымда мин жараусыз мяндяңя котолоу бир, Минем уйларымны Ўзеңнен арыу Евангелиеңне аңнаулык жактысы белян жактырт, жанымны Качыңны сөйөўлек белян, кюңелемне таза, изге сюзлярең белян, тянемне няпеслярне басылдыра торган азабларың белян, уйымны Ўзеңнен жыуашлыгың белян саклаб, тейешле багытта мине Ўзеңне даннарга торгоз. Син була башлаган чагы жук Атаҥ

белян, иң изге арыу Тының белян гумергя даннаулы шул, аминь.

3-нче иман, тере итеуче изгелекле Святый Тынга

Эй Ходай, кюк Падшасы, жанга тынычлык, кюңелгя чын белем биреўче Тын, изгелекле кюңелең белян мин жазыклы мяндяңне жарлыкаб, мин тейешсез мяндяңя бөгөнге жазыкларымны барында ташла, кичер, ädям кюк мин бөгөн жазыкландым, ädям кюк кня төгөл, ämмя терлеклярдян дя начарырак кыйландым. Минем иректян, ирексездян, белеб, жя белмей кылган жазыкларым, жяштян начарлыкка кюнеккяннектян, оятсызлыктан, өмөтсезлектян, Синең исемең белян карганган булсам, жя кюңелем белян исемеңне курлаган булсам, беряўне-беряўне тиргягян булсам, ачыуланыб äляклягян булсам, жя кайгырткан булсам, жя бер-бер нястягя ачыуланган булсам, жя алдалаган булсам, жя тейешсез багытта жоклаб жаткан булсам, жя минем катка жарлы килеб, аны кабыл алмаган булсам, жя туганымны кайгырткан булсам, жя беряўне айыблаган булсам, жя мактанган булсам, жя олосомакланган булсам, жя ачыуым килеб

жарсыган булсам, жя мин теляктя торганда, уйым бу дöньянен начарлыгына ауышкан булса, жя арулыктан ауышыуны уйлаган булсам, жя артык ашаган булсам, жя артык эчкян булсам, жя тилереб кölгян булсам, жя начар эшлярне уйлаб жöргян булсам, жя кешедя äйбят äйбер кюреб, анҙар кюнҙелемне салган булсам, жя тейешсез сюз сöйляшкян булсам, жя туганымнын жазыгыннан кölгян булсам, минем шул жазыкларым санаб бетергесез, жя теляк итяргя жалкауланган булсам, жя бютян тагы исемя килмей торган жаман эшлярем булса, алары бу äйткянняремнян дя кюберяктер. Шунҙар кюря эй мине Булдырыучы, Башкарыучы, мин ömötсез, тейешсез мяндянгне жарлыкаб Ўзең кеше сöйöўче изгегя кюря, миңа ташла, чиш, кичер. Мин жазыклы, азгын, жараусыз тынычланыб жоклаб тönnö ўткярсям эйе. Аннары Сиңа табыныб, иң кядерле исемеңне Ата белян, Анын жангыз тыуган Улы белян жырлаб даннасам ыйы, äле дя äр чакта да гумердян гумергя, аминь.

4-нче иман, изге оло Макарийнеке

Эй безгя кюб арыулыклар биргян ўлемсез Падша, кеше сöйöўче жумарт Ходай! Мин Синға ней китерейем, Синға ней кайтарыйым, мин Синға жараулыны кыларга жалкауланыб ич тя арыулык кылмаган мяндяґне шушы узган кöннöн азагына китереб житкезденґ. Жаным тяўбя итеб котолошло итеб тöзялгян. Мин жазыклыга, äр бер арыу эшкя жалангачка изгелекле бул. Минем чамасыз жазыклар белян шакшыланыб жыгылган жанымны кютяреб торгоз. Бу кюреня торган тормошнон жаман уйларын бöтöнняй миннян алыб ташла. Эй бер гня жазыксыз Ходай, миґа жазыкларымны кичер, бöгöнге кöннö ней белян гня булса да, белеб, жя белмей сюз белян, эш белян, уй белян, бар тойоноуларым белян жазыкланган булсам да миґа кичер. Син Ўзенґ мине Аллалык кыуатыґ белян, яйтеб житкезеўсез сöйöўлегенґ какына, äр-тöрле карышыучы нястялярдян жабыб сакла. Эй Аллам, Ўз кыуатыґ белян мине тазарт, минем кюб жазыкларымны тазарт. Эй Ходай мине жаманнын ауыннан котолдороб, минем жанымны коткарыб, зур дан белян килгян чагында жöзöґнен жактысы белян мине

жактыртырга ризалык ит. Хязердя айыбланмыйчы жоклаб китсям эйе. Мин мяндянгнен кюнгеленя тёрле уйлар китермейче саклаб, шайтаннын ăр-бер эшлярен миннян кыуыб жибяр. Минем кюнгелемнен акыл кюзлярен жактырылдыр, мин ӳлем жокосо белян жокламасам ыйы, минем жанымны да, тянемне дя сакларга ёйрятеӳче, тынычландырыучы, саклаучы Пяриштянгне жибяр, ул мине дошманнарымнан аралаб алсын ыйы, мин урнымнан тороб Синга тау итеӳ теляге китерсям эйе. Эй Ходай, мин жазыклы, ăр-тёрле тыйнаклыктан жарлы мяндянгне эшет. Мин урнымнан торгач Синенг сюзляреня ёйрянсям эйе. Ӳз пяриштялярең белян жаман тын жибяря торган моңайыулыкны жырак кыуыб жибяр. Синенг арыу исеменгне тау итеб даннасам ыйы, Алланы тыудырган ин таза Кыз Марияны да жалан даннасам ыйы, Син Аны без жазыклыларны жаклаучы итеб биргян, Анын безнен ёчён иткян теляген кабыл ал. Ул да Синенг кеше сёйёӳчелегеня ошашлы булыб, безнен ёчён теляк итеӳдян туктамаганны мин белямен, Анын жаклауы буйынча, бар изгелярең какына эй Аллабыз Іисусъ Христосъ, кядерле Качынгнын билгесе белян, изгелеген

какына минем жарлы жанымны саклаб тор, Син даннаулы гумергя, аминь.

5-нче иман

Эй Ходай Аллабыз, бөгөн эш белян булса да, сюз белян булса да, уй белян булса да кылган жазыкларымны барысын да Син изгелеген какына, ädямне сöйöүлеген какына миңа кичер, Миңа ряхят, тыныч жоко бир, äр-төрле усал нястядян жабыб сакларга Пяриштянне жибяр. Жаннарыбызны, тянняребезне саклаучы Син Ўзең. Син Атага, Улга, Святый Тынга дан китерябез, äле дя äр чакта да гумердян гумергя, аминь.

6-нчы иман

Эй без ышана торган Ходай Аллабыз, без Синең исеменя бютян äр бер исемнян дя бигеряк сыйынабыз, без жокларга тороучыларга, жаныбызга да, тянебезгя дя тынычлык бир. Äр-төрле жаман, азгын уйлардан безне сакла, безнен тян няпесляребезне басылдыр, безгя эшляребездя дя, сюзляребездя дя шиксез тороргa кыуат бир, без, Син безгя бирясе изгелеклярдян буш

калмас өчөн арыу эшляр гня кылыб торсак ыйы, Син шул гумергя даннаулы, аминь.

7-нче иман, изге Иоаннъ Златоустныкы, көн белян төн сягятляре исябенчя

Көндөзгеляре: Эй Ходай, Син мине кюктяге дяўлятеңнян буш калдырма, эй Ходай, мине мянге азабтан коткар. Эй Ходай, уй белян, жя исяб белян, жя сюз белян, жя эш белян кылган жазыкларымны кичер. Эй Ходай, мине акылга китер, онотолдорма, жанымны жөдяўгя калдырма, каты кюңелемне жомошат. Эй Ходай, мине ăр-төрле алданыудан сакла, эй Ходай, минем азгыннык карангыландырган кюңелемне жактырт. Эй Ходай, мин жазыклы кеше, Син кызганыучан Алла, Син минем ăлсезлянгян жанымны кюреб, мине жаклыка. Эй Ходай, миңа Синең арыу исемеңне даннатырлык, жакшы эшляр кыларга кыуатыңны биреб булыш. Эй Ходай Іисусъ Христосъ, мин мяндяңне терелек княгяседя жаз, ўлгяч миңа арыу урын бир. Эй Ходай Аллам, минем Синең алдында кылган бер дя жакшы эшем жук, Син миңа Ўз изгелегеңнян арыу тормош башларга кыуат бир, Эй Ходай, минем кюңелемне Ўз изгелеген белян

жомошатыб арыула. Эй кюкне, жирне булдырган Ходай, мин усал, карангы, жирянгеч мяндянне падшалыгында исеня ал, аминь.

Тёндягеляре: Эй Ходай, мин тяўбягя килеўчене кабыл ал, жазыкларымны кичер, эй Ходай, мине ташлама, миня булыш. Эй Ходай, мине тыгызлыкка туры китермя, эй Ходай, миня арыу исяб бир. Эй Ходай, ўлясемне исемя китереб, кюнелемне жомошатыб мине жылат. Эй Ходай, жазыкларымнан кайтырга миня сагыш бир, эй Ходай, мине жыуашландыр, кюнелемне тазарт, кушкан сюзне тынналучан ит. Эй Ходай, мине тюземне ит, чыдам жанны ит, сабырлыклы ит. Эй Ходай, Синнян куркыудан ăр-тёрле арыу эшляр буладыр, айса Син Ўзенгнян мине Ўзенг куркыт. Эй Ходай, буган жанымнан, буган уймнан Сине сёйёб, бар эшемне дя Син кушканча кыларга миня кыуат бир. Эй Ходай, мине усал кешелярдян, шайтаннардан, напеслярдян, ăр-тёрле жарамаган эштян коткар. Эй Ходай, Син Ўзенг дигянчя кыласынг, Синенг иркенг мин жазыклыга да булсын, Син мянгегя данналыб торасынг шул, аминь.

8-нче иман Ходайыбыз Иисусъ Христоска

Эй Ходайым Іисусъ Христосъ Алла Улы, Синеҥ кядерле Таза Анаҥнын, тянсез Пяриштярeҥнен, алдыҥнан килеўче чумылдырыучы пягямбяр Іоаннын, Алланы сöйляўче апостолларнын, арыулык белян жиҥгян жакты мученикларнын, кюнгеллярендя Алланы жöрткян жараулы аталарыбызнын, бар äўлеялярнен дя телякляре какына, мин мяндяҥне äле миҥа киля торган женнярнен ауларыннан котолдор. Эй Ходайым, Булдырыучым, Син жазыклынын ўлеўен телямейсеҥ, äммя жазыгыннан кайтыб тере тороуын телейсеҥ. Мин бичарага да жазыгымнан кайтырга булыш, харяб итеўче жыланнын сызгырыб, жотоб, тере кöйö тамукка тöшöреўеннян мине аралаб ал. Эй Ходайым, минем тынычлыгым, мин бичара öчöн, Син минеке кюк тянгя кейенгян, бичаралыктан мине жолоб чыгар. Мине мескен жаныма тынычлык бир. Минем кюнгелемя начар эшлярне ташлаб, Син кушканны кылыу уйын бир. Шулай итеб, Син бирясе рахятлекне алсам ыйы, Сиҥа öмöтляндем, эй Ходай, мине сакла.

9-нчы иман, Алланы тыудырган иң изге Кыз Марияга

Аллабызнын Син иң кядерле Таза Анасына, буганнарнын Кыз Падшасына, мин мескен жыгылыб инялямен; Мин туктаусыз жазыкланыб, Синең Улың минем Алламнын ачыуын китерямен, кюб табкыр тяўбягя килсям дя Алла алдында алдаучы гна буламын, ялля инде Ходай мине бётённяй ўк бетерер микян диб, калтраныб кна тяўбя итямен. Ўзем шуннан суң тагынук шуны кыламын. Эй Алланы тыудырган оло Башкарыучыбыз, мин мыны белеб Синға инялямен: мине жарлыкасаң ыйы да, арыулык кыларга кюңелемне ныгайтсаң ыйы. Эй Башкарыучы Алланы тыудырыучы, Син белясең ич; мыннан ары мин ўземнен жаман эшляремне кюрялмас булганымны да, ямма бар кюңелем белян Алламнын законын сёйгянемне. Эй иң Таза, оло Башкарыучы, тик белмейем бит: нишляб кюрялмый торган нястямне тагы сёям суң, ямма арыулыкны кылмыйым. Эй иң таза Кыз, Син Ўзең миңа ўз иркемне кыларга ирек бирмя, ул бит жараулы эш тёгёл, ямма миндя Синең Улың минем Алламнын ирке булсын,

ул мине коткарсын, акылга кертсен, Святый Тыннын дяўлятен бирсен эйе, мыннан былай мин шакшы эшлярне кылыудан туктасам ыйы да, Синеӈ Улыӈнын кушканын кылыб торсам ыйы. Анӈар äр-төрлечя даннау, кядерляў, тотоучылык тейешле, була башлаусыз Атасы белян, тере итеўче изгелекле Святый Тыны белян äле дя äр-чакта да гумердян гумергя, аминь.

Алла Анасына тагы иман

Эй изге Падшанын изгелекле Анасы, Алланы тыудырган даннаулы иӈ кядерле Мария, Ўз Улыӈ безнен Аллабызнын изгелеген минем няпесле жаныма индереб, теляклярең белян мине жакшы эшляр кыларга öйрят. Мин калган гумер көнняремне жазыксыз ўткязеб, Синеӈ арткылы жомак табсам ыйы, эй Алланы тыудырган Кыз, Син кядерле, даннаулы бер гня.

Саклаучы Пяриштягя иман

Эй Христосъ Пяриштясе, мине саклаучы изге, бöгöн кылган жазыкларымны барында кичер, усал дошманнын äр-төрлечя алдауыннан мине коткар, бер жазык белян дя

Алламнын кятерен калдырмасам ыйы. Мин жазыклы, усал мяндя өчөн теляктя бул, Святый Өч Ипостасле Алланын да, Ходайым Іисусъ Христоснын Анасынын да, бютян äўлеялярнен дя изгелекляреня тейешле итеб кюрсят мине, аминь.

Кондак Алла Анасына

Эй Алланы тыудырган Кыз! Син чиреў башлыгыдый безгя булышыб, дошманнарыбыз-ны жиңдереб безне кысанныктан коткарганга, без мяндялярең тау итеб Сине ололаб данныйбыз, карысында бер дя тора алмаслык кыуатың, белян äр-төрле бялядян безне коткар, без дя Синға былай äйтейек: эй кядерле, арыу Кыз, сөйөн!

Эй Алла Христоснын Анасы, жалан таза көйö тороучы изге Кыз, телягебезне Ўз Улың Аллабыз алдына китер, Синең какыңа жаннарыбызны коткарсын ыйы.

Бар өмөтемне Синға саламын, эй Алла Анасы, мине Ўзең жабыб сакла.

Эй Алланы тыудырган Кыз, мин Синең булышыуыңны, Синең жаклауыңны киряксеня торган жазыклы мяндяңнян жөзөңне борма, минем жаным Синға өмөтлянде, мине жарлыка.

Изге атабыз Иоанникий Великийнен иманы

Минем ышанганым Ата, минем сыйынганым Ул, мине жабыучы Святый Тын, эй Святый Өчлө, шөкөр Синға.

Чыннаб дөрөс тейешле, эй Алланы тыудырган Кыз, Сине кядерлярга, Син мянге кядерле, шиксез, таза, Син безнен Аллабызнын Анасы: Херувимнярдян дя кядерле, Серафимнярдян дя данны, Кыз көйө Сюз Алланы тыудырган, чын Алла Анасы Сине ололойбыз.

Шөкөр Атага, Улга, Святый Тынга, әле дя әр чакта да гумердян гумергя, аминь.

Эй Ходай жарлыка, эй Ходай жарлыка, Эй Ходай жарлыка.

Эй Ходайым Іисусъ Христосъ Алла Улы, Синең кядерле, таза Анаңнын да, кюнеллярендя Алланы жөрткян арыу тормошло аталарыбызнын, бар әүлеялярненгнен дя телякляре какына мин жазыклыны да коткара кюр.

Изге атабыз Иоаннъ Дамаскиннын иманы

Мыны жатасы урнынгны кулынг белян кюрсятеб укы.

Эй безне тотоб Тороучы, ädямне сöйöўче Ходай! Бу жатыр урын минa ällя инде гроб булыр микян, ällя минем жанымны тагы кöн жактыртырсынгмы? Мына минем алдымда гроб жата, мына минем карышымда ўлем тора. Эй Ходай Синең хöкöменгнян дя, мянге азабтан да куркамын, ämмя ўзем усаллык кылыудан тукталмыйым. Син Ходай Алламнын кятерен туктаусыз калдырамын, Синең кядерле Анаңнын да, кюктяге бар чиреўлярнен дя, мине саклаучы Пяриштямнендя кятерен калдырамын. Шунныктан эй Ходай, Синең сöйöўлегенә тейешле тöгöл икяннегемне, ämмя äр-тöрле айыбланыуга, азабка тейешле икянемне белямен. Эй Ходай, алай булса да телясям дя, телямясям дя мине Ўзең коткара кюр. Син жараулыны гна коткарсаң алайук зур изгелек тöгöл, жя чистаны гна жарлыкасаң ис китярлек тöгöл, андыйлар Синең изгелегенә тейешле шул, ämмя мин жазыклыга Ўзенгнен изгелегенгне кюрсят. Шунын белян Ўзенгнен кеше сöйöўлегенгне аңнат, минем усаллыгым Синең äйтеб житкезмяслек изгелегенгне, озак

тўзеўенгне алыб узмасын ыйы, шулай Ўзенг телягянчя эшляренгне булдыр мин мяндянгя, аминь.

Урнынга жатыр алдыннан быларны укы.

Эй Алла Христосъ, кюзляремя жактыны кюрсят, жоклаганда ўлмясям эйе, дошманым аны жингдем диб кыуанмасын ыйы.

Шёкёр: Эй Алла Син минем жанымны саклаучы бул, мин кюб тозаклар арасында жёрёймен, алардан мине коткар, Эй кеше сёйёўче Изгелекле, мине сакла.

Ёле дя: Алланын арыу пяриштялярдян дя ин арыу, бик кадерле Анасын, кюнгел белян дя, тел белян дя туктаусыз данныйык, эй Алланы тыудырган диб, Ул Ўз эчендя Алланы тянняндереб тыудырган шул, безнен жаннарыбыз өчёндя туктаусыз инялеб торадыр.

Аннары ўзенгнен качынгны ўб, жата торган урынга башынгнан аягынга чаклы кач кыл, шулай тёрле жакка да кач кыл, шул чакта тере итеўче ***кядерле Качка*** *шушы иманны укы:*

Алла торсон, Анын дошманнары таралышыб бетсенняр, Аны кюрялмый торганнар Анын жёзённян качсыннар, тётён

таркалыб беткян шикелле таркалыб бетсенняр, утта балауыз эреб беткян шикелле, Алланы сöйöўчелярдян: ўзляреня Кач билгесен кылыб, кыуанышыб, эй Ходайнын терелек биря торган иң кядерле качы сöйöн, синдя кадакланган Ходайыбыз Іисусъ Христоснын кыуаты белян син женнярне кыуасың, Ул тамукка тöшöб, шайтаннын кöчöн бетереб, син кядерле Качны безгя äр-бер дошманны кыуарга биргян диб äйтеўчелярдян женняр качсыннар. Эй Ходайнын терелек биря торган иң кядерле Качы, Алланы тыудырган Башкарыучы изге Кыз белян, бар изгеляр белян бергя миңа гумергя булышыб тор, аминь.

Шулай кач кылганда былай кыскача итеб тя äйтергя жарый:

Эй Ходай, терелек биря торган кядерле Качыңнын кыуатын äйлянямдя тотоб, мине äр-тöрле жаманнан сакла.

Аннары калдык сорау көнөн исенә төшөрөб, Алла карышысына килеб жауаб бирсенгне уйлаб, ўзенә кач кылыб, иман белян жоклаб кит.

Аулакта яйтеля торган иманнар.

Эй Алла, иректян, иреҗсездян, жя сюз белян, жя эш белян, жя белеб, жя белмей, жя көндөз, жя төння, уйыбыз, сагышыбыз белян кылган жазыкларыбызны ташла, кичер, бетер, барында кичер безгя, Син кеше сөйөўче, Син изгелекле.

Эй кеше сөйөўче Ходай, безне кюрялмаганнарга, рянжеткяннярга кичер, безгя жакшылык кылганнарга Син дя жакшылык кыл. Кярендяшляребезгя, жакыннарыбызга котолоу турысында телягяннярен булдырыб, мянге тормош бир, чирляб жатыучыларны изгелек белян килеб төзят, дингездя жөрөўчелярне туры алыб бар. Жулчыларга жулдаш бул, чын денне тотоучыларга дошманнарын жинеш. Безгя жакшылык иткяннярнен, безгя кезмят иткяннярнен жазыкларын кичер. Без жараусызларга ўзляре өчөн теляк итягя кушканнарны Ўзенгнен оло изгелегенгнян жарлыка. Эй Ходай, элеке ўлгян

аталарыбызны, кярендяшляребезне исенҙя ал, аларны Ўз жактыҥ жактырта торган урынга кертеб тынычландыр. Эй Ходай, тотконга алынган туганнарыбызны исенҙя ал, аларны ӓртөрле кысанныктан коткар. Эй Ходай, арыу Жыйынга пайдалы эш кылыучыларны исенҙя ал, аларны котолоуны телягяннярен булдыр, аларга мянге тормош бир, эй Ходай, без жазыклы, жараусыз мяндяряреҥне дя исенҙя ал, Ўзеҥне белеўлек белян акылыбызны жактырылдыр, бойорокларыҥнын жулына безне керт, Алланы тыудырган иҥ Таза, жалан Кыз көйӧ торучы изге Мариянен, буган ӓўлеяряреҥнен телякляре какына, Син шул гумергя даннаулы, аминь.

Жазыкларыҥны берян-берян иска алыб, аларны Ходайга ӓйтеб тяўбя итеў иманы

Моны кич тя, иртян дя ӓйтергя жарый.

Эй мине Булдырыучы Ходай Аллам, Ўзе бер, иҥ Святый Өчлӧ диб, без данный торган, табына торган Ата, Ул, Святый Тын, мин ўз гумеремнен бар көннярендя дя кылган жазыкларымны ӓйтеб Синҙа тяўбя итямен; Ӓрбер сягяття, кязерге багытта да узган көннӧ дя, узган төндя дя жазыкландым. Мин эшем белян,

сюзем белян, уйым белян, артык ашау белян, эчкелек белян, жяшертен ашау белян, буш сюзляр белян, жукка моңайыу белян, жалкаулык белян, карышы äйтеў белян, тыңнаусызлык белян, äлякляў белян, кеше тикшереў белян, саксызлыгым белян, ўземне гня сöйöў белян, кюб äйбер жыйыу белян, урлау белян, дöрöс сöйляшмягянем белян, шакшыланыб жöрöўем белян, дöрöссöзлöк няпесен сöйöў белян, кönняшеў белян, кеше тормошона кönчöлöк итеў белян жарсыуым белян, усаллыкны истя тотоуым белян, кюремсезлек белян, малга биренеўлек белян, аннары бар саннарымнын тойоноулары белян, кюз кюреўем белян, колагым эшетеў белян, ис тойоуым белян, ашамнык тяме тойоу белян, кармалаб каруым белян, тагы да бютян тöрлö жан жазыклары белян дя, тян жазыклары белян дя Син Алламнын кятерен калдырдым, жакынима да дöрöссöзлöк кылдым. Шушылар öчöн ўкенеб, ўземне айыблаб Син Аллам карышысына китерямен, тяўбя итяргя мина да ирек бар диб белямен. Эй Ходай Аллам, кюз жяшем белян жыуашланыб Синнян телеймен: Син Ўзең гня мина булыш, шушы узган багытта кылган жазыкларымны Ўзеңнен изге

кюнеллеген какына мина кичер, шушы Синең карышында äйткянняремнен барысыннан да мине иркенгя чыгар, Син изге, кеше сöйöўче шул, аминь.

Эй Ходай, тынымны Синең кулына табшырамын, Син мине жарлыка, Син мине бахилля, жаныма мянге тере тороулык бир, АМИНЬ.